ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

« 28 » март 2016 ел                                                  № 333

**2016 елда эшсез гражданнар өчен җәмәгать эшләрен оештыру турында**

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 19.04.1991 ел, №1032-1 (22.12.2014 ред.) федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Эшсез гражданнарга өстәмә социаль ярдәм күрсәтү һәм халыкны вакытлыча эш белән тәэмин итү максатларында җәмәгать эшләрен оештыру турында Нигезләмәне раслау хакында» 1997 елның 14 июлендәге 875 номерлы карары (25.03.2013 ред.) нигезендә Арча район башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елда эшсез гражданнар өчен җәмәгать эшләрен оештыру буенча Арча муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре исемлеген расларга (1 нче кушымта);

2. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. «Арча районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ эш бирүчеләр белән түләүле җәмәгать эшләрен оештыру турында шартнамәләр төзергә.

2.2. Әлеге предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләренә гражданнар тарафыннан эшкә җибәрелә торган вакытлы килешүләр төзүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны үтәгәндә мәшгульлек хезмәте һәм эш бирүчеләр акчалары исәбеннән гражданнарның мәшгульлеген оештыру турындагы Нигезләмәгә халыкның мәшгульлегенә булышлык итү һәм эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чараларын финанслау тәртибе турындагы нигезләмәдә каралган суммалар чикләрендә таянырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.И. Гарифҗановка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе                                        И.Ә.Галимуллин

*Арча муниципаль районы башкарма комитетының ______ 2016 ел,№ ______ карарына 1 нче кушымта*

2016 елда эшсез гражданнар өчен җәмәгать эшләрен оештыру буенча Арча муниципаль районы предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары

*ИСЕМЛЕГЕ*

| № т/б | Предприятие исеме | Кеше саны | Эш төре | Дәвамлылыгы | Эшне башкару чоры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | "ЖКБС" ҖЧҖ | 39 | Төзекләндерү һәм яшелләндерү | 1 ай. | I-IV кв. |
| 2 | «Агрохимия» ҖЧҖ | 9 | Ярдәмче эшләр | 1 ай. | II-III кв. |
| 3 | «Төзелеш материаллары комбинаты» ҖЧҖ | 3 | Төзекләндерү, ярдәмче эшләр | 1 ай. | II-III кв. |
| 4 | "Шанс" ҖЧҖ | 6 | Ремонт эшләре, төзекләндерү | 1 ай. | II-IV кв. |
| 5 | "Энергосервис" ҖЧҖ | 9 | Ярдәмче эшләр | 1 ай. | I-IV кв. |
| 6 | "Стройжилсервис" ҖЧҖ | 9 | Ярдәмче эшләр | 1 ай. | II-III кв. |
| 7 | Утар Аты авыл җирлеге башкарма комитеты | 9 | Төзекләндерү, ремонт эшләре, ярдәмче эшләр | 1 ай. | I-IV кв. |
| 8 | Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитеты | 9 | Ярдәмче эшләр | 1 ай. | I-IV кв. |
| 9 | Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитеты | 9 | Ярдәмче эшләр | 1 ай. | I-IV кв. |
| | БАРЛЫГЫ | 102 | | | |

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә.Галимуллин